КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2021 ел, 1 ноябрь г.Казань № б-2182

Татарстан Республикасының сәнәгать һәм сәүдә предприятиеләрен квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү буенча тәкъдимнәр әзерләү максатларында:

1. Татарстан Республикасында сәнәгать һәм сәүдә тармакларын кадрлар белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча эшче төркем төзергә.

2. Бу боерыкка теркәлгән Татарстан Республикасында сәнәгать һәм сәүдә тармакларын кадрлар белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча эшче төркем турындагы нигезләмәне һәм аның составын расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 1 ноябрь, б-2182 нче
боерыгы белән расланды

# Татарстан Республикасында сәнәгать һәм сәүдә тармакларын кадрлар белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча эшче төркем турында нигезләмә

1. Татарстан Республикасында сәнәгать һәм сәүдә тармакларын кадрлар белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча эшче төркем (алга таба – эшче төркем) Татарстан Республикасының сәнәгать һәм сәүдә предприятиеләрен квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү буенча тәкъдимнәр әзерләү максатларында төзелде.

2. Эшче төркем үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указларына һәм боерыкларына, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актларына, бу Нигезләмәгә таянып эш итә.

3. Эшче төркемнең төп функцияләре түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасының сәнәгать һәм сәүдә предприятиеләрен кадрлар белән тәэмин итү өлкәсендәге вәзгыятьне анализлау;

Татарстан Республикасының сәнәгать һәм сәүдә предприятиеләрен кадрлар белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр әзерләү.

4. Үз функцияләрен гамәлгә ашыру өчен эшче төркем түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, мәгариф һәм башка оешмалардан билгеләнгән тәртиптә мәгълүмат һәм документлар соратып алырга;

фәнни оешмаларны, галимнәрне һәм белгечләрне үз эшенә җәлеп итәргә.

5. Эшче төркем составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы белән раслана.

6. Эшче төркем үз эшчәнлегендә дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, мәгариф оешмалары белән хезмәттәшлек итә.

7. Эшче төркем кирәк булганда үз утырышларына предприятиеләрнең, мәгариф һәм башка оешмаларның вәкаләтле вәкилләрен чакырырга мөмкин.

8. Эшче төркем утырышлары кирәк булуга карап үткәрелә.

Эшче төркем рәисе утырышларда рәислек итә, көн тәртибен раслый, эшне планлаштыра һәм эшче төркем карарларын тормышка ашыруны тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра. Эшче төркем рәисе булмаганда, рәис функциясен, рәис белән килештереп, урынбасарларының берсе башкара.

Утырышлар үткәрү датасы, вакыты, урыны һәм көн тәртибе, эшче төркем әгъзаларыннан керә торган тәкъдимнәрне исәпкә алып, рәис яки рәис урынбасары тарафыннан раслана.

Эшче төркем утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, хокуклы дип санала. Төркем утырышында әгъза булмаган очракта, ул карала торган мәсьәләләр буенча үз фикерен язма рәвештә тәкъдим итәргә хокуклы.

Карарлар утырышта катнашучы әгъзаларның күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, эшче төркем утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып тора.

Эшче төркем карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм аңа утырыш үткәрелгән көннән җиде эш көне эчендә рәислек итүче тарафыннан имза куела. Эшче төркем утырышының имзаланган беркетмәсе һәм аның кушымталары күчермәсе алга таба эшләү өчен өч эш көне эчендә эшче төркем әгъзаларына, шулай ук утырышта катнашкан предприятиеләр, мәгариф һәм башка оешмалар вәкилләренә электрон рәвештә җибәрелә.

9. Эшче төркем эшчәнлеген оештыру ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 1 ноябрь, б-2182 нче
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасында сәнәгать һәм сәүдә тармакларын кадрлар белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча эшче төркем составы

| | |
|---|---|
| Кәримов Альберт Әнвәр улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры, эшче төркем рәисе |
| Карпов Родион Михайлович | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары, рәис урынбасары – эшче төркем секретаре |
| Поминов Андрей Иванович | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары, эшче төркем рәисе урынбасары |
| Таҗетдинова Клара Алексеевна | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары, эшче төркем рәисе урынбасары |

Эшче төркем әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Афанасьев Михаил Павлович | Зеленодольск муниципаль районы башлыгы (килешү буенча) |
| Бәдриев Илдар Фоат улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе башлыгы |
| Галиев Ренат Марат улы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе (килешү буенча) |
| Гобәйдуллин Әгъзам Самат улы | «Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча) |
| Дмитриев Виктор Петрович | Татарстан Республикасының Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе (эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе) генераль директоры урынбасары (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Кондратова Наталья Владимировна | Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары |
| Лаврентьев Александр Петрович | Татарстан Республикасының Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе (эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе) президенты (килешү буенча) |
| Мәһдиев Наил Гамбәр улы | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Метшин Илсур Рәис улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Муллин Рамил Хамзә улы | Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |
| Нагуманов Тимур Дмитриевич | Әлмәт муниципаль районы башлыгы (килешү буенча) |
| Нәфыйгин Альберт Илдар улы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе (килешү буенча) |
| Нуриев Рөстәм Мидхәт улы | Алабуга муниципаль районы башлыгы (килешү буенча) |
| Пахомов Алексей Михайлович | Татарстан Республикасының Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе (эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе) генераль директоры (килешү буенча) |
| Ушенин Александр Михайлович | «КАМАЗ» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директорының персонал белән идарә итү буенча урынбасары (килешү буенча). |